# Татарстан Республикасы
# Дәүләт Советы Президиумы
# КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Дәүләт гимны текстының иң яхшы проектына иҗади конкурс үткәрү турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 121 статьясы, "Татарстан Республикасы дәүләт символлары турында" Татарстан Республикасы Законы нигезендә, җәмәгатьчелек вәкилләре мөрәҗәгатен исәпкә алып, патриотизм тәрбияләү, граждан аңын формалаштыру, Татарстан Республикасы халыкларының дуслыгын һәм бердәмлеген ныгыту максатларында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. 2012 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт гимны текстының иң яхшы проектына иҗади конкурс үткәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт гимны текстының иң яхшы проектына иҗади конкурс үткәрү турындагы нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

3. Татарстан Республикасы Дәүләт гимны текстының иң яхшы проектына иҗади конкурс үткәрү буенча комиссия составын расларга (2 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслауны күздә тотуны тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе урынбасары — А.П. Гусев

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты. Аппарат Государственного Совета Республики Татарстан. БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ. ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2011 елның 15 декабре
№ 1946-IV ДС

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының 2011 елның 15 декабрендәге 1946-IV ДС номерлы карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Дәүләт гимны текстының иң яхшы проектына ижади конкурс үткәрү турында**

**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Дәүләт гимны текстының иң яхшы проектына ижади конкурс (алга таба – конкурс) үткәрүне оештыру шартларын һәм тәртибен билгели.

1.2. Конкурс Россия Федерациясе граждан законнары таләпләре нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт гимны (алга таба – гимн) текстын булдыру максатында үткәрелә.

1.3. Конкурс үткәрүне оештыру өчен конкурс комиссиясе (алга таба – Комиссия) төзелә.

2. Конкурс үткәрү шартлары

2.1. Конкурста профессионал шагыйрьләр, үзешчән авторлар, ижат коллективлары катнашырга мөмкин. Конкурс комиссиясе әгъзасы ижади конкурста катнашырга хокуксыз.

2.2. Гимн тексты патриотизм хисен, тарихка ихтирамлы мөнәсәбәтне, Татарстан халыкларының бердәмлеген һәм дуслыгын, аларның мәдәни һәм көнкүреш традицияләрен чагылдырырга тиеш.

2.3. Гимн текстлары конкурска Татарстан Республикасы дәүләт телләренең берсендә яисә икесендә дә тәкъдим ителә.

Гимн тексты гимн көенең (композитор Рөстәм Яхин) характерына, темпына, үлчәменә һәм ритмикасына туры килергә тиеш.

2.4. Конкурска, Россия Федерациясе граждан законнарында билгеләнгән авторлык хокукларын үтәп, яңа әсәрләр дә, элек басылып чыккан әсәрләр дә тәкъдим ителергә мөмкин.

2.5. Конкурс ике этапта үткәрелә:

беренче этап – өч иң яхшы гимн тексты проектын алдан сайлап алу;

икенче этап – гимн текстының, гимн көе характерына, темпына, үлчәменә һәм ритмикасына туры килүен исәпкә алып, иң яхшы проектын сайлап алу.

2.6. Конкурска материаллар 1 номерлы һәм 2 номерлы ябыштырылган ике конвертта һәр конвертта "Татарстан Республикасы Дәүләт гимны" тамгасы һәм

конкурста катнашучының коды (кодлы сүз, фраза, девиз) белән, фамилиясе (фамилияләре) күрсәтелмичә тапшырыла.

Конкурста катнашу өчен түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

1 номерлы конвертта: конкурс эше – конкурста катнашучының коды күрсәтелеп, басма рәвештә гимн тексты проекты;

2 номерлы конвертта: конкурста катнашучының (катнашучыларның) шәхси белешмәләре (фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы, паспорт белешмәләре, тору урыны адресы, контакт телефоны номеры) күрсәтелеп, конкурста катнашуга заявка;

әгәр гимн тексты проекты иҗат коллективы тарафыннан әзерләнсә, әлеге коллективның барлык әгъзалары имзалаган, иҗат коллективы әгъзалары арасында акчалата премияне процентлап бүлү турында тәкъдим;

конкурста катнашучы (катнашучылар) җиңүче дип танылган очракта, аның (аларның) гимн текстына аерым хокукларын Россия Федерациясе граждан законнары таләпләре нигезендә Татарстан Республикасына түләүсез тапшыруы турында язма йөкләмәсе.

2 номерлы конверт конкурсның беренче этабына йомгак ясалганнан соң гына ачыла.

2.7. Гимн текстының конкурска тәкъдим ителгән проектлары рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

2.8. Конкурска тәкъдим ителгән, билгеләнгән таләпләргә туры килми торган материаллар, шул исәптән билгеләнгән срокны бозып бирелгәннәр дә, конкурста катнаштырылмый.

2.9. Конкурста катнашу өчен материаллар 2012 елның 1 июленә кадәр түбәндәге адрес белән җибәрелә: 420060, Казан шәһәре, Ирек мәйданы, 1, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, "Татарстан Республикасы Дәүләт гимны" тамгасы белән. Белешмәләр өчен телефоннар: (8-843) 267-63-94, 267-64-51.

## 3. Комиссия эшчәнлеген оештыру

3.1. Комиссия эшчәнлеге коллегиаль рәвештә гамәлгә ашырыла.

3.2. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, тулы хокуклы була.

3.3. Комиссия карарлары Комиссия әгъзаларының гомуми саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә. Комиссия әгъзаларының карарны хуплап яисә аңа каршы бирелгән тавышлары саны тигез булган очракта, Комиссия рәисе тавышы хәлиткеч була.

3.4. Комиссия:

конкурста катнашу өчен гимн тексты проектларын кабул итү яисә конкурс таләпләренә һәм шартларына туры килмәгән очракта аларны кире кагу мәсьәләләрен хәл итә;

конкурсның беренче һәм икенче этаплары барышында гимн текстының иң яхшы проектларын билгели;

конкурска гомуми йомгак ясый һәм аның нәтиҗәләре турында карар кабул итә;

кирәк булганда, Татарстан Республикасы Президиумына гимн текстының иң яхшы проектын Татарстан Республикасының икенче дәүләт теленә тәрҗемә итүне оештыру турында тәкъдим кертә;

конкурста катнашучыларның мөрәҗәгатьләрен карый;

конкурс үткәрүгә бәйле башка мәсьәләләрне хәл итә.

3.5. Комиссия рәисе Комиссия эшен оештыра, утырышлар үткәрү вакытын һәм урынын билгели, Комиссия утырышының көн тәртибен билгели.

3.6. Комиссия секретаре утырышлар үткәрүгә әзерлекне оештыра, шул исәптән Комиссия әгъзаларына утырышларны үткәрү урыны һәм вакыты турында хәбәр итә, Комиссия утырышлары өчен кирәкле материалларны әзерли, Комиссия утырышларының беркетмәләрен алып бара һәм карарларын әзерли.

3.7. Комиссия үз эшенә экспертлар җәлеп итәргә хокуклы, шул исәптән шартнамә нигезендә дә.

3.8. Комиссия утырышлары һәм Комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа Комиссия рәисе һәм секретаре имза сала. Конкурсның гомуми йомгаклары Комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

## 4. Конкурсның беренче, икенче этапларына йомгак һәм гомуми йомгак ясау

4.1. Конкурсның беренче этабына йомгак Комиссия тарафыннан 2012 елның 1 октябренә кадәр ясала. Яшерен тавыш бирү нәтиҗәләре буенча Комиссия карары белән гимн текстының өч проекты сайлап алына.

4.2. Конкурсның икенче этабына йомгак Комиссия тарафыннан 2012 елның 1 ноябренә кадәр ясала. Гимн текстының иң яхшы проекты яшерен тавыш бирү нәтиҗәләре буенча Комиссия карары белән билгеләнә. Комиссия карары белән конкурс уздырылмаган дип танылырга мөмкин.

4.3. Комиссия карары һәм гимн тексты Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумына тәкъдим ителә.

4.4. Комиссия тәкъдим иткән материаллар буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы "Татарстан Республикасы Дәүләт символлары турында" Татарстан Республикасы Законы белән расланган гимн көенә гимн тексты проектының туры килүен билгеләү һәм Комиссия тарафыннан алдан тыңлауга версияләр (гимн вариантлары: тавыш һәм симфоник оркестр; хор һәм симфоник оркестр; тавыш, хор һәм симфоник оркестр; башкару һәм студиядә яздыру) сайлап алу өчен белгечләр җәлеп итә. Кирәк булганда, гимн тексты проектын Татарстан Республикасының икенче дәүләт теленә тәрҗемә итү оештырылырга мөмкин. Гимн текстының ахыргы проекты ике дәүләт телендә версияләрнең төрле вариантларда башкарылган музыкаль язмасы белән бергә Комиссиягә тапшырыла.

## 5. Йомгаклау нигезләмәләре

5.1. Гимн текстының иң яхшы проекты Комиссия тарафыннан ике дәүләт телендә версияләрнең төрле вариантларда башкарылган музыкаль язмасы белән

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумына 2012 елның 31 декабренә кадәр җибәрелә.

5.2. Гимн тексты проектының конкурста җиңүче дип танылган авторына (авторларына) 200 мең сум күләмендә акчалата премия түләнелә. Конкурсның икенче этабына узган, ләкин җиңүче дип танылмаган текстлар авторларына 50 шәр мең сум кызыксындыру премияләре түләнә.

5.3. Җәлеп ителгән белгечләргә эш йомгаклары буенча акчалата бүләк түләнә. Гимн тексты Татарстан Республикасының икенче дәүләт теленә тәрҗемә ителгән очракта тәрҗемә авторына (авторларына) акчалата бүләк түләнә.

5.4. Конкурста җиңгән гимн текстына аерым хокуклар Татарстан Республикасы милкенә күчә.

5.5. Гимн тексты Татарстан Республикасы законы белән раслана.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының 2011 елның 15 декабрендәге 1946-IV ДС номерлы карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Дәүләт гимны текстының иң яхшы проектына конкурс үткәрү буенча комиссия**
**СОСТАВЫ**

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Ратникова<br>Римма Атлас кызы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Комиссия рәисе |
| 2. | Исаева<br>Анастасия Георгиевна | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе урынбасары, Комиссия секретаре |
| 3. | Абдуллин<br>Рубин Кәбир улы | Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе ректоры (килешү буенча) |
| 4. | Алешков<br>Николай Петрович | шагыйрь, Россия Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге идарәсе әгъзасы (килешү буенча) |
| 5. | Андреева<br>Людмила Николаевна | Казан шәһәр Думасы секретаре (килешү буенча) |
| 6. | Владимиров<br>Николай Михайлович | Татарстан халыклары Ассамблеясы Советының Башкарма комитеты җитәкчесе – Совет Рәисе урынбасары |
| 7. | Воронова<br>Людмила Яковлевна | Казан (Идел буе) федераль университетының рус әдәбияты тарихы кафедрасы мөдире, доценты (килешү буенча) |
| 8. | Гыйльметдинов<br>Илдар Ирек улы | Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты (килешү буенча ) |
| 9. | Грицких<br>Владимир Иванович | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, "Шәһәрне үстерү буенча бюджеттан тыш программалар дирекциясе" ААҖ генераль директоры |
| 10. | Ибраһимов<br>Илфак Мирза улы | Татарстан Республикасы Язучылар берлеге рәисе (килешү буенча) |
| 11. | Кәлимуллин<br>Рәшит Фәһим улы | Татарстан Республикасы Композиторлар берлеге рәисе (килешү буенча) |
| 12. | Латышев<br>Александр Николаевич | "Республика Татарстан" газетасы баш мөхәррире (килешү буенча) |

| | | |
|---|---|---|
| 13. | Липужина<br>Валентина Николаевна | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты рәисе |
| 14. | Миңнуллин<br>Туфан Габдулла улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Республикасы халык язучысы |
| 15. | Мушинский<br>Әхәт Хәй улы | "Казанский альманах" журналының баш мөхәррире (килешү буенча) |
| 16. | Нигъмәтуллина<br>Гөлшат Рәдиф кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| 17. | Салихова<br>Зөлфирә Якуб кызы | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының сәнгатьләрне үстерү һәм авторлык хокукларын яклау бүлеге мөдире |
| 18. | Сәфәров<br>Миңназыйм Мәүлет улы | "Ватаным Татарстан" газетасының баш мөхәррире (килешү буенча) |
| 19. | Сөнгатуллина<br>Зилә Даян кызы | Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе профессоры, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы (килешү буенча) |
| 20. | Терентьев<br>Александр Михайлович | Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| 21. | Яһудин<br>Шакир Шәяхмәт улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты рәисе |